Исполнительный комитет
Бизякинского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
ул. Центральная д. 46, с. Бизяки
Менделеевский район, 423648

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә
Үз җирлеге башкарма комитеты
Үзәк урамы, 46, Бәзәкә авылы,
Менделеевск районы, 423648

тел./факс (85549)3-47-34

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 152 01.11.2023 ел

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
“Бәзәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Бәзәкә авыл җирлеге уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 2 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 йорт адресы буенча урнашкан Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Кәшәфетдинов И.И. – Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Садриев М.Ф. – Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге рәисе урынбасары»;

Кәшәфетдинов И.Р.. – Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге депутаты (килешү буенча).

3. 2023 елның 1 ноябреннән 2023 елның 1 декабренә кадәр « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш проекты буенча материаллары экспозициясен Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 йорт адресы буенча урнашкан Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 432648, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк ур., 46 йорт (Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының

рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә

Бәзәкә авыл җирлеге  башлыгы            И.И.Кәшәфетдинов